**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы даими вәкиллеген үзгәртеп кору турында**

Татарстан Республикасы һәм Севастополь шәһәре арасында үзара файдалы сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәдәни һәм гуманитар багланышларны киңәйтү һәм ныгыту максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы һәм «Татарстан Республикасының вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы даими вәкиллеген Симферополь шәһәрендә урнашачак Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы һәм Севастополь шәһәрендәге даими вәкиллеге итеп үзгәртеп корырга.

Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы һәм Севастополь шәһәрендәге даими вәкиллеге Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы даими вәкиллегенең, төзелгән килешүләрдә һәм шартнамәләрдә каралган йөкләмәләр буенча да, хокукый дәвамчысы булып тора дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы даими вәкиллеген Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы һәм Севастополь шәһәрендәге даими вәкиллеге итеп үзгәртеп кору белән бәйле чаралар комплексын тормышка ашыруны тәэмин итәргә;

бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы һәм Севастополь шәһәрендәге даими вәкиллеге нигезләмәсен эшләргә һәм Татарстан Республикасы Президенты каравына тәкъдим итәргә;

Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы һәм Севастополь шәһәрендәге даими вәкиллеген финанслау чыганакларын һәм тәртибен «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган акча кысаларында билгеләргә, аның структурасын һәм штат санын расларга;

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләренә законнар нигезендә Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы даими вәкиллеген Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы һәм Севастополь шәһәрендәге даими вәкиллеге итеп үзгәртеп кору белән бәйле гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

үзенең актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2010 елның 22 апрелендәге ПУ-254 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 декабрендәге ПУ-863 номерлы, 2011 елның 5 мартындагы ПУ-108 номерлы, 2011 елның 1 июнендәге ПУ-298 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-676 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-189 номерлы, 2012 елның 28 маендагы ПУ-395 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-648 номерлы, 2014 елның 3 мартындагы ПУ-235 номерлы, 2014 елның 20 мартындагы ПУ-286 номерлы һәм 2014 елның 29 мартындагы ПУ-338 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасына, 5 бүлектә «Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы даими вәкиллеге» сүзләрен «Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы һәм Севастополь шәһәрендәге даими вәкиллеге» сүзләрен алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 29 гыйнварындагы ПУ-80 номерлы, 2014 елның 10 февралендәге ПУ-132 номерлы, 2014 елның 5 мартындагы ПУ-244 номерлы, 2014 елның 20 мартындагы ПУ-286 номерлы, 2014 елның 19 апрелендәге ПУ-405 номерлы, 2014 елның 26 апрелендәге ПУ-435 номерлы, 2014 елның 2 июлендәге ПУ-636 номерлы, 2014 елның 12 сентябрендәге ПУ-854 номерлы, 2014 елның 28 ноябрендәге ПУ-1091 номерлы, 2014 елның 5 декабрендәге ПУ-1107 номерлы һәм 2015 елның 16 мартындагы ПУ-289 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санына, 51 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| «51 | Татарстан Республикасының Кырым Республикасындагы һәм Севастополь шәһәрендәге даими вәкиллеге | 3». |

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 18 март
№ ПУ-294